ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 86 от «01» 03 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның 9 августындагы
262 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге № 605-ФЗ Федераль законга таянып, Башкарма комитет җитәкчесенең 2022елның 22 февралендәге «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 47 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 9 августындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 262 номерлы карарына (алга таба- карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукларын гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милек бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының (6 нчы кушымта) 2.9.2. пунктында «күчемсез мөлкәт» сүзен «арендага бирелә торган» сүзенә алмаштырырга, «арендага бирелә торган» сүзен «мондый» сүзенә алмаштырырга, «күчемсез мөлкәт өчен һәм күчемле мөлкәт өчен кимендә өч ел» сүзләрен өстәргә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов